## КАРАР

**23 ноябрь, 2023 ел** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 23 ноябрендә 14.00 сәгатьтә һәм 2023 елның 23 ноябрендә 18.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»

500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү
- янгын гидранты һәм комплектлау өчен детальләр сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)
- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)
- Совет урамы тыкрыгын төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)
- ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, ял итү зоналарын төзекләндерү; Сабантуй бәйрәме уздырыла торган урын территориясен төзү һәм төзекләндерү; (сәхнәне, тамашачылар өчен эскәмияләрне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү; материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)
- Зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү (инструментлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)
- Сууткәргеч челтәрләрен һәм су суырту манараларын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (Байлангар авылында су суырту манараларын буяу, артезиан скважинасы өчен насослар сатып алу, материаллар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)
- Урам яктыртуны карап тоту; (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү)

- Байлангар авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

- Байлангар авылы урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю (килешү буенча түләү)
- Байлангар авылының Гагарин урамына асфальт җәю
- Байлангар авылында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)
- Байлангар авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү , килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 514 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **259** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 256 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»

1100 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су суырту манарасы сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре;
- янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре;
- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, Байлангар авылы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре;
- Совет урамы тыкрыгын төзү, карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Совет урамы тыкрыгын төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- массакүләм ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт мәйданчыклары, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннары) һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, массакүләм ял итү урыннарын урнаштыру, карап тоту, төзекләндерү һәм җиһазландыру буенча башка эш төрләре;

- зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, кораллар һәм инвентарь сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;

- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- Байлангар авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- юлларга вак таш һәм асфальт салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- Байлангар авылында автомобиль күперен төзү һәм ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, башка эш төрләре;

- Байлангар авылындагы чишмәне төзекләндерү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материаллар сатып алу, чишмә территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин